Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Комсомола, д. 4а,
с. Старый Кашир, 423357.
Телефон: (85559) 4-86-36
E-mail: Sksr.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Комсомол урамы, 4а йорт,
Иске Кәшер авылы, 423357.
Телефон: (85559) 4-86-36
E-mail: Sks.Sar@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 нче ел 15 нче март № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма комитетының 22.12.2015 ел, № 11 карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентның үз көчен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр керту хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр керту турында» 2020 елның 4 сентябрендәге 1355 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма комитетының 22.12.2015 ел, № 10 карары белән расланган җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламент үз көчен югалткан дип санау (23 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма
комитет житәкчесе Р.Н.Дәүләтҗанов